Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

20 апрель 2022 ел № 144

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 16 декабрендәге 343, 2021 елның 11 мартындагы 40, 2021 елның 17 июнендәге 58 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымта 2 бүлекнең 2.2 пунктындагы 3 пунктчасы унөченче абзацын «Район башкарма комитеты вәкаләтләре» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәһәр ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен федераль закон нигезендә кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итә».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Н.В. Парфилова) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т. Д. Нагуманов